**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

10.02.2020 № 78

**Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты составына үзгәрешләр кертү турында**

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының «Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариатын оештыру турында» 2019 елның 26 гыйнварындагы 65 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Дәүләт советының «Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр тирәлеге» юнәлеше буенча эш төркеме секретариаты (алга таба – секретариат) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

секретариат составыннан А.Р. Гатиятовны чыгарырга;

секретариат составына кертергә:

Азин Юрий Николаевичны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге башлыгын;

Вилданов Данис Фәнил улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасарын;

Хәнифов Фәрит Мөдәррис улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрын;

секретариат әгъзасы И.Ә. Фәйзуллинның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, секретариат җитәкчесе урынбасары (килешү буенча)»;

секретариат әгъзасы Н.Л. Фишманның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Фишман-Бикмәмбәтова».

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ